**Ялалова Рәмзилә Габделхәй кызы**



Чибәр, ягымлы Ялалова Рәмзилә Габделхәй кызы үзенең хезмәт юлын 1974 елда Тат.Буләр мәктәбендә пионервожатый булып башлый. Шунда эшләгәндә, Нур Шәех улы белән гаилә кора. 1977 елны Үрәзмәт урта мәктәбенә биология укытучысы итеп күчерелә. Ул мәктәптә 7 ел эшли. Укучыларның иң яраткан укытучыларының берсе була.Тырыш, инициативалы, белемле,талантлы укытучыны тиз күреп алалар, һәм ул "Хезмәт уңышлары өчен" медале белән бүләкләнә.1984 елда Мәлләтамак мәктәбендә биология һәм химия укыта башлый. Шул елларда мәктәп профсоюз председателе була һәм профсоюз өлкә комитетының Грамотасы белән бүләкләнә. 1994 елдан лицейга күчә. Лицейда үрнәк география кабинеты булдырып, район конкурсында беренче урынны ала. 2000 елдан район география укытучыларының методик берләшмәсе җитәкчесе була. 2008 елда Казанга президент М.Ш.Шәймиев белән очрашуга да бара. 2009 елда "Гражданлык һәм патриотизм турында XXI гасыр укытучысы" дигән Бөтенроссия конкурсы лауреаты була.Рәмзилә Габделхәй кызы шигырьләр сөйләргә һәм җырларга да бик оста. Газета-журналларда да даими мәкаләләре басылып тора. Өч баласы да, әниләренә ошап, мәктәпне алтын медальгә, ә югары уку йортларын кызыл дипломга тәмамлыйлар. Укучылары да яраткан укытучыларын онытмыйлар, хәл белеп, киңәш сорап, бәйрәмнәр белән котлап кына торалар.